**ГЛАВА ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2023 елның 12 октябре | № 1

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 24 октябрендә «Нур» кибете янында (Үзәк ур., 75) Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. 2023 елның 24 октябрендә Үзәк ур., 25 йорт янында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. 2023 елның 24 октябрендә Шахмай авыл мәдәният йортында (Үзәк ур., 45) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Халык җыенын үткәрү өчен Шахмай авылында яшәүчеләр исемлеген аеруны сайлау тәртибен вакытлыча билгеләр буенча башкарырга кирәк.
5. Халык җыенын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы белән тәэмин ителә.
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, моннан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән һәм контракт буенча хезмәт итүче гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче, 1 Төркем инвалидларыннан һәм алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонт, коймалар төзү.

«ӘЙЕ» «ЮК».».

7. Әлеге карарны гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет «мәгълүмат-телекоммуцион челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://pravo.tatarstan.ru., Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авылындагы мәгълүмат стендында,Шахмай авылы, Үзәк урам, 47 нче йорты янында.

8. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы

СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Н.М.Илалова